РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12,
г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 21 феврале № 13

Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 21 мартындагы 13 номерлы карары белән расланган (Түбән Кама шәһәр Советның 2017 елның 24 гыйнварындагы 4 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 14 номерлы, 2019 елның 17 маендагы 23 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 21 мартындагы 13 номерлы карары белән расланган (Түбән Кама шәһәр Советның 2017 елның 24 гыйнварындагы 4 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 14 номерлы, 2019 елның 17 маендагы 23 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрләрнең класслы чиннары» 7 статьясында 7.2 пунктында «Татарстан Республикасында» сүзләрен «Түбән Кама шәһәрендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында мәгълүмат бирү» 14.1 статьясында:

а) 14.1.2 пунктында «әлеге статьяның 1 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 14.1.1 пунктында» сүзләренә алмаштырырга, «(2 нче кушымта)» сүзләрен «(1 нче кушымта)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 14.1.3 пунктында «әлеге статьяның 1 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 14.1.1 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. «Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы» 26 статьясында 26.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «26.3. Дисциплинар җәза куллану һәм аклау тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

1.4. «Муниципаль берәмлектә кадрлар эше» 28 статьясында 12 пунктында «әлеге Федераль законның» сүзләрен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 24 гыйнварындагы 4 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә

муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 21 мартындагы 13 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары белән расланган 2 нче кушымтаның нумерацион исеменә түбәндәге сүзләр өстәргә: «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта».

2. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт узуга кагылышлы норматив хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин